Тема: Гомәр Бәштровның “Туган ягым –яшел бишек” әсәре.

Дәреснең максатлары:

Белем бирү: “ Туган ягым –яшел бишек” әсәрен өйрәнүне дәвам итү, әсәрдә күтәрелгән проблемаларны ачыклау

Тәрбияви: “Туган ягым-яшел бишек” әсәре аша, укучыларда кече Ватанга, милләтебезгә, гореф-гадәтләребезгә, бәйрәм-йолаларыбызга карата хөрмәт һәм горурлык хисләре тәрбияләү, туган якка, гади авыл кешеләренә ихтирам, игътибарлылык уяту.

Материал:

- Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы;

Дәрес барышы

I. Дәресне оештыру. Укучылар белән исәнләшү.

--Хәерле көн,укучылар, исәнмесез.

II. Мотивлаштыру – ориентлаштыру:

–Балалар, дәресебезне башлап җибәрәбез. Бүген без төркемнәрдә эшләрбез (1 нче төркем –кызлар, 2нче төркем –егетләр,3нчесе – “Туган ягым –яшел бишек” әсәренең төп герое Гомәрләр гаиләсе).

(Кунак кыз килеп керә)

Кунак кыз :

-Исәнмесез, исән генә яшисезме? Менә күчтәнәчләр рәхим итеп алыгыз (чәкчәк бирә). Гомәр дә зур үскән икән инде.

Гомәр:

-Әйдә, рәхим ит. Кил, утыр.

Әнисе :

-Түрдән уз,кызым.Кадерле кунагыбыз булырсың.

Әтисе :

-Утырышыгыз өстәл янына. Кил,кызым, утыр, юлда килеп арыгансыңдыр, чәй эчеп алырбыз.

Гомәрнең апасы :

-Бик әйбәт булды әле килүең, бергәләп Сабан туена дип сөлгеләр чигәрбез.

- Укучылар, бу кем килде диеп уйлыйсыз?

- Кунак кызы килде.

-Бик, дөрес укучылар.

-Ни өчен килде икән ул?

-Кунакка килде.

-Дөрес. Бу –бүгенге дәресебезнең темасы. Без "Туган ягым-яшел бишек" әсәрен өйрәнүне дәвам итәбез. "Кунак кызлар килде утырмага" дигән өлеше дәреслегебезнең 44нче битендә бирелгән. Анда кунакка килде димәгән, утырмага килде дип бирелгән. Утырма сүзе ни аңлата.Кунак кызы, аңлатып бир әле.

Кунак кызы :

-Утырма сүзе татар телендә берничә мәгънә белдерә. Менә аның аңлатмалы сүзлектә бирелгән мәгънәләре:

**УТЫРМА**

**1.** исем. **СЫЕКЛЫКТА НИНДИ ДӘ БУЛСА МАТДӘНЕҢ ТӨПКӘ УТЫРГАН ВАК КИСӘКЛӘРЕ;**

**организмдагы тоз утырмасы — отложе́ние соле́й в органи́зме**

**үсемлек маендагы утырма — оса́док в расти́тельном ма́сле**

**2.** *сыйф..*;**КАЙТАРЫП КУЕЛМЫЙ ТОРГАН, ТУРЫГА БАСТЫРЫП КУЕЛГАН;**

**утырма яка — стоя́чий воротни́к**

**3.** исем *.этногр.*

1) **ХАТЫН –КЫЗЛАРНЫҢ ҮЗ ТУГАННАРЫНДА ОЗАКЛАП КУНАК БУЛУ ЙОЛАСЫ;**

2) **ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ КУЛ ЭШЕ БЕЛӘН КИЛЕП КИЧ УТЫРУ ЙОЛАСЫ**

**кызлар утырмага килгән — де́вушки пришли́ на посиде́лки**

-Укучылар, без бүген туганнарында озак вакыт кунак булу дигән мәгънәсенә тукталабыз.

-Гомәр, әсәрдә Гомәр Бәширов кунак кызын нинди итеп сурәтләгән, эзләп таптыңмы әсәрдән, бу биремнәр сезгә алдан бирелгән иде?

Гомәр :

-Кунак кызы яшь кенә,чәчләре башка кызларныкы кебек кара я коңгырт түгел, бодай саламы төсле.Бите озынчарак, күзләре күк төсле. Иреннәре бөрлегән төсле.Бит урталары алма кебек алсуланып тора. Чәче тарап үргән, чулпылар таккан, көмеш балдаклар кигән.

- Балалар, Гомәр Бәширов, менә шул кечкенә генә өзектә нинди сурәтләү чаралары кулланган? Төркемнәрдә уйлыйбыз.

- Кайсы төркем җавап бирә?

Гомәрләр гаиләсеннән апасы

җавап бирә:

- Әлеге өзектә язучы чагыштырулар кулланган: чәчләре бодай саламы төсле, күзләре күк төсле, иреннәре бөрлегән төсле, бит урталары алма кебек.

-Рәхмәт.Балалар, килешәсезме?

-Төркемнәргә тагын бер бирем. Без кунак кызының тышкы кыяфәтен карап киттек. Хәзер кызлар төркемендәгеләр үзләрен кунак кызы ролендә дип уйлап, егетләр хыялларын кушып , кунак кызының эчке сыйфатларын фаразлыйбыз. Алдыгызда “Фаразлар агачы” ята. Тиз генә шуларны тутырабыз. (Төркемнәрдә эш)



-Фаразларыбызны яздык. Кем җавап бирә? Егетләрдән .... тыңлыйбыз.

(1 укучы җавап бирә)

-Рәхмәт. Кем өстәмәләр кертә? Кызлар төркеме ничек уйлый?

(1 укучы җавап бирә)

- Рәхмәт.Укучылар, барыгызга да сорау: кунак кызлары нинди максат белән, ни өчен килгәннәр икән? Дәреслегебезнең 45нче битеннән эзлибез. Үзлектән эш. Җавапны әзерләдегез, куен дәфтәренә (блокнот) язып куйдыгыз.,

-Ә хәзер егетләр төркемендәге һәр егет кызлар төркеме янына барып, кемне дә булса сайлап ала, кунак кызларының ни өчен килүе турында сораша һәм үз фикерләрен дә аңа әйтә, уртак фикергә киләләр. Аннан башка кыз янына барып сораша (броун хәрәкәте)Гомәрләр гаиләсе үз төркемнәрендә җавап әзерләп, кәгазьгә язып куя.).

–Укучылар, вакыт бетте. Бер кызны, бер егетне тыңлыйбыз. ...., сиңа сүз.

(Кунак кызлары озак итеп кунак булырга дип башка авылдагы туганнарына барганнар).

- .....тыңлыйбыз.

(Әсәрдә язучы кыш башында өмәләр башлана, шул вакытта кунак кызлары килеп төшә дип язган. Димәк, алар төрле өмәләрдә булышырга дип килгәннәр).

-Гомәрнең әнисенә сүз бирәм, кызлар, егетләрнең фикере дөресме?

(Кунак кызлары утырмага, беренчедән, озаклап торып кунактан кунакка йөрергә дип, икенчедән, каз өмәсе, сүс өмәсе, тула өмәсе дип аталган өмәләрдә катнашырга дип килгәннәр).

-Укучылар, хәзер барыбыз да менә бу шакмакларга карыйбыз. Андагы рәсемнәрне нинди тезмә берләштерә. Төркемнәр уйлый.



-......, нинди уртаклык бар бу рәсемнәрдә?

(Рәсемнәрдә татар халкының милли йолаларыннан берсе- Каз өмәсе сурәтләнгән).

-Әйеме, кунак кызы?

Кунак кызы:

-Әйе дөрес, чөнки кунак кызлары да өмәләрдә катнашкан.

-Сүзне Гомәрнең әтисенә бирәбез. Каз өмәләре ничек үткән, ...?

Гомәрнең әтисе:

-Мин җавабымны видеоязма формасында әзерләдем. Игътибар белән карагыз. (видеоязма карала).

**Каз өмәсе** - көзен, кыш кергәндә казларны өмәләп эшкәртү чарасы. Ул матур итеп күңел ачу чарасы да.Татар яшьләре каз өмәсен аеруча көтеп ала торган булганнар.. Йолкыган казларны көянтәгә асып кызлар чишмәгә, су буена алып төшкәннәр. Шул суда казларны юганнар. Гармуннар тагып, кызлар белән бергә егетләр дә чишмәгә тәшкән.Хуҗабикә коймак,каз бәлеше пешереп, чәй әзерләп кичке мәҗлес әзерләгән.Казларны кайтарып элгәч, чәчәкле яшел, зәңгәр чиләкләрен көянтәгә асып кызлар чишмәдән су ташыганнар. Бу өйдәге генә түгел, күрше –күләннең дә су савытларын тутырганнар, әллә ничә тапкыр су алырга барганнар,җиңел итеп очып кына йөргәннәр, гүя аяклары да җиргә тимәгән. Өсләрендә яңа күлмәкләр, кешелеккә генә кия торган бишмәт, аллы –гөлле шәлләр.Егетләр күпер төбендә гармунда уйнаганнар, җырлаганнар.Кичен йортта яшьләр уены оештырылган.

-Укучылар, каз өмәсеннән соң, яшьләр күңел ачкан, бәйрәм ясаган. Ничегрәк икән? ..., син ничек уйлыйсың?

(Җырлаганнар, биегәннәр, уеннар уйнаганнар, минемчә).

-Балалар, нинди татар халык уеннарын беләсез?

(“Йөзек салыш”, “Кәрия-Зәкәрия, “Ак калач”, “Яулык салыш”, “Урындыклар”, “Миңлебай”).

1 укучы:

-Әйдәгез бергәләп уен уйнап алабыз. “Йөзек салыш” уены. Барыбыз да тиз генә тезелеп бастык. (Укучылар ярымтүгәрәк ясап басалар). Мин алып

баручы.(Укучыларның барысын да йөгереп уза, йөзекне .... сала). Кемдә йөзек сикереп чык. (..сикереп чыга).

-..... бик уңган, зирәк кыз икән, йөзек аңарда булганын сизми калдыгыз.

1 укучы:

-Әйдәгез тагын бер кат уйныйбыз. “Йөзек салыш” уены. Укучыларның барысын да йөгереп уза, йөзекне ... сала). Кемдә йөзек сикереп чык. (...укучылар тотып кала).

1 укучы:

-... җиңелде.

1 укучы:

-... нинди җәза бирәбез?

1 укучы:

-Җырласын әле матур итеп.

... (уйланып тора):

-Җырламыйм, белемегезне тикшереп карыйсым килә.Сорау: Гомәр Бәширов кайда туган?

(Арча районының Яңасала авылында туган).

...:

Икенче соравым: “Туган ягым –яшел бишек” нинди әсәр?

(Ул Гомәр Бәшировның үз тормышыннан алып язылган автобиографик әсәр).

...:

-Әсәрнең төп герое кем?

(Повестьнең төп герое –Гомәр).

-Укучылар, ял итеп алдык. Хәзер куен дәфтәрләрегезне ачыгыз да, анда сезнең үзбәя бите бар, шунда бүгенге дәрес өчен билге куегыз (Укучылар блокнотларын ачып, билге куялар).

(Музыка яңгырый.)

-Укучылар, ишетәсезме җырны? Бу “Никрутлар җыры” дигән мөнәҗәт. Кем ул никрут?  Безнең әсәр белән нинди бәйләнеше бар? Әлеге сорауга җавап табу  өчен сез өйдә “Туган ягым –яшел бишек” әсәренең калган өлешен укып бетерергә тиеш буласыз. Сау булыгыз.Дәрес өчен рәхмәт.